**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 23 апрель № 278

г. Казань

Казан шәһәре, Академик Королев урамы, 28 йорт адресы буенча урнашкан бина фасадына мемориаль такта кую турында

1941 – 1945 еллар Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 70-еллыгын бәйрәм итү кысаларында, күренекле авиаконструктор, беренче дәрәҗәдә Сталин премиясе лауреаты, ПЕ-2 һәм ПЕ-8 бомбардировщикларын уйлап табучы Петляков Владимир Михайлович хәтерен мәңгеләштерү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Петляков Владимир Михайлович 1941 елдан алып 1942 елгача яшәгән Казан шәһәре, Академик Королев урамы, 28 йорт адресы буенча урнашкан йорт фасадына мемориаль такта кую турында, рус һәм татар телләрендәге түбәндәге текст белән, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, “Туполев” ачык акционерлык җәмгыяте филиалы – С.П.Горбунов исемендәге Казан авиация заводы тәкъдимен кабул итәргә:

“В этом доме в 1941 – 1942 гг.
жил выдающийся авиаконструктор,
создатель бомбардировщиков ПЕ-2 и ПЕ-8
Владимир Михайлович Петляков

———————

1941 – 1942 елларда бу йортта
күренекле авиаконструктор,
ПЕ-2 һәм ПЕ-8 бомбардировщикларын уйлап табучы
Владимир Михайлович Петляков яшәгән”.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\278.doc